| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Зеленодольск шәһәре** **КАРАР**

**03.07.2026** **№ 2310**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе турында» 2021 елның 24 мартындагы 60 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.
2. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе эш регламентын (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе вәкаләтләре чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм биш ел тәшкил итә.
4. Түбәндәге карарларны үз көчләрен югалткан дип танырга:

-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 15 июлендәге 1674 номерлы карары;

-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында » 2024 елның 13 маендагы 1281 номерлы карары;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының « Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 июлендәге 1674 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе эш регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 гыйнварындагы 16 номерлы карары;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 24 февралендәге 636 номерлы карары.

5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 03 июлендәге
2310 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Краснобаев Евгений Васильевич | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |

**Рәис урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Архипов Денис Владимирович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һәм хезмәтләр күрсәтү бүлеге начальнигы |

**Җаваплы секретарь:**

| | |
|---|---|
| Хохлова Ирина Николаевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгече |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Сергеев Павел Николаевич | «Зеленодольск муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе |
| Абросимова Ольга Михайловна | «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ – техник инспекциясе идарәсе» МКУ начальнигы |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 03 июлендәге
2310 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе эш тәртибе**
**РЕГЛАМЕНТЫ**

Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы административ комиссиясе (алга таба - административ комиссия) эш тәртибен билгели.

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, район территорияләрен төзекләндерүне тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль хокукый актлар һәм әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия - Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә эш итә.

1.4. Административ комиссиянең бурычлары - Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба - РФ КоАП) һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы (алга таба-ТР КоАП) нигезендә административ хокук бозу турындагы һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, чыгарылган карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү.

1.5. Административ комиссиясе вәкаләтләре чоры беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә. Күрсәтелгән срок тәмамлангач, административ комиссия үз вәкаләтләрен яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр башкаруын дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән очракларда вакытыннан алда туктатыла. Административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән соң бер ай эчендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән административ комиссиянең яңа әгъзасы билгеләнә.

1.7. Административ комиссия төзү һәм эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны түбәндәгеләр контрольдә тота:

- җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тиешле дәрәҗәдә гамәлгә ашыру өлешендә юстиция өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

- -Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы ;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты.

1.8. Административ комиссия үзенең тулы исеме язылган мөһеренә ия.

## II. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм административ комиссия әгъзаларыннан тора. Административ комиссиянең персональ һәм сан составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән кимендә 5 кешедән билгеләнә һәм парсыз санны тәшкил итәргә тиеш.

2.2. Рәис административ комиссиянең эшчәнлеген җитәкли һәм аның эшен оештыра.

2.3. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.4. Административ комиссия үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар нигезендә алып бара. Административ комиссиянең агымдагы эше рәис тарафыннан расланган план буенча алып барыла.

2.5. Административ комиссия рәисе урынбасар белән җаваплы секретарь арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели, бу тиешле боерык белән беркетелә.

2.6. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә. Кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

2.7 Административ комиссия адресына килгән шикаятьләр һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.8. Административ комиссиянең квартал хисаплары Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча әзерләнә.

2.9. Административ хокук бозулар турындагы эшләр, Федераль архив агентлыгы тарафыннан расланган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган типовой идарә итү архив документлары исемлегенә кертелде. Эшләр административ комиссия урнашкан урында законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда саклана.

2.10. Мөрәҗәгать итүчеләргә, законнарда каралган очраклардан тыш, карар чыгарганчы, административ хокук бозулар турында эшләрне бирү тыела.

## III. Утырыш алып бару тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән билгеләнгән срокларда тәэмин ителә.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр рәислек итүче, җаваплы секретарь, комиссия әгъзалары, эштә катнашучы башка затлар һәм аларның вәкилләре катнашында административ комиссия утырышларында карала.

3.3. Утырышта административ комиссия рәисе рәислек итә, ә ул булмаган очракта – аның урынбасары.

3.4. Административ комиссия утырышлары ачык була. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала. Административ комиссия карары белән утырышлары ябык булырга мөмкин. Аларда комиссия әгъзалары, хокук саклау органнарының вазифалы затлары һәм махсус чакырылган затлар катнаша.

Комиссиянең ябык утырышлары административ хокук бозу турындагы эш карала торган затның үтенечнамәсе буенча уздырыла, әгәр бу административ хокук бозу турындагы эш буенча производствода катнашучы затларның, аларның гаилә әгъзаларының, аларның якыннарының иминлеген тәэмин итү, шулай ук күрсәтелгән затларның намусын һәм абруен яклау мәнфәгатьләрен таләп итсә.

Административ хокук бозу турындагы эшне ябык карау турындагы карар административ комиссия тарафыннан билгеләмә рәвешендә чыгарыла.

3.5. Утырышлар закон таләпләрен үтәп, утырышлар залында үткәрелә, утырышлар залы булмаганда эшләрне башка урыннарда карау рөхсәт ителә.

3.6. Административ комиссия утырышында административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3.7. Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео- һәм фотосъемка административ комиссия рәисе рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

3.8. Административ комиссия утырышын әзерләүне җаваплы секретарь башкара, ул карауга билгеләнгән административ хокук бозулар турында эшләр исемлеген төзи, рәислек итүчегә эшне карау мөмкинлеге турында хәбәр итә, якларның килүен һәм вәкаләтләрен тикшерә, шулай ук өстәмә материаллар килүен тикшерә.

3.9. Административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен билгеләнгән вакытка рәислек итүче утырышны ача, комиссия составын игълан итә, катнашучыга эш буенча хокук һәм бурычларны аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процессында катнашучыларның гариза, үтенечнамәнең бармы-юкмы икәнлеген ачыклый, утырыш белән җитәкчелек итә, эшнең барлык шартларын тулысынча ачыкларга ярдәм итә, утырыш барышында тиешле тәртипне саклауны тәэмин итә.

3.10. Административ хокук бозу турындагы эшне карау рәислек итүченең административ материалда бәян ителгән хәлләр турындагы докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.11. Утырыш комиссиясе докладыннан соң административ хокук бозу турындагы эш буенча фикер алышуга күчә, анда комиссия әгъзалары гына катнаша.

3.12. Административ комиссиянең һәр утырышында административ хокук бозу турындагы эшне карау турында беркетмә алып бару мәҗбүри.

3.13. Административ хокук бозу турындагы эшне карауны кичектерү, тәнәфес игълан итү һәм яңадан карау гамәлдәге закон таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

3.14. Административ хокук бозу турындагы эшне карап тикшергәннән соң административ комиссия карар чыгару өчен тәнәфес игълан итә, бу хакта рәислек итүче утырыш залында катнашучыларга хәбәр итә.

3.15. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.16. Комиссия утырышы атна саен үткәрелә, 9.00 сәгатьтә башлана һәм, комиссия тарафыннан башка карар кабул ителмәсә, төшке ашка тәнәфес белән, 16.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча тәмамлана.

## IV. Административ комиссия карары

4.1. Административ комиссия карарына рәислек итүче кул куя, ә ул булмаганда – административ комиссия рәисе урынбасары.

4.2.Бер үк вакытта утырышта катнашучы затларга һәм аларның вәкилләренә административ комиссия карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

4.3. Карарның күчермәсе расписка белән физик затка яисә физик затның законлы вәкиленә яисә юридик затның законлы вәкиленә тапшырыла йә күрсәтелгән карар чыгарылган көннән алып өч көн эчендә күрсәтелгән затларга җибәрелә.

4.4. Административ комиссия карарлары күчермәләрен үз вакытында тапшыру һәм җибәрүне контрольдә тоту җаваплы секретарьгә йөкләнә.

4.5. Административ комиссия карарларына шикаятьләр яисә протестлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## V. Административ җәза салу турындагы карарның үтәлеше

5.1. Административ хокук бозу турындагы эш буенча административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

5.2. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, законлы көченә кергәннән соң үтәлергә тиеш.

5.3. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан, административ штраф салу турында карар законлы көченә кергән көннән яки Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында кодексының 31.5 статьясы белән каралган кичектерү яки бүлеп түләү вакыты чыккан көннән соң, алтмыш көннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

5.4. Административ штраф суммасы Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында билгеләнгән административ штрафлар буенча җирле бюджет керемнәре администраторының реквизитлары буенча муниципаль хокукый актларны бозган өчен административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан кертелә яисә күчерелә.

5.5. Административ штраф түләү турында таныклый торган документ булмаганда, карар закон көченә кергән көннән түләү өчен билгеләнгән срок тәмамлангач, административ комиссия федераль законнарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен тиешле материалларны суд пристав-башкаручысына җибәрә.

5.6. Штраф салу рәвешендәге административ җәза гаепле затларны рөхсәт ителгән җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгыннан азат итми.

## VI. Административ хокук бозуларны профилактикалау

6.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия үз эшчәнлеген контрольләүче органнар, Татарстан Республикасы буенча суд приставлары Федераль хезмәте идарәсенең территория бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

6.2. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эш оештыра.

## VII. Административ штрафны түләмәгән затларга карата административ хокук бозу турында беркетмә төзү

7.1. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә административ комиссиянең вәкаләтле затлары административ штраф түләмәгән затларга карата Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында беркетмәләр төзиләр.

7.2. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турындагы беркетмәләр җәмәгать судьяларына карауга җибәрелә.